КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 сентябрь г.Казань № 871

Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын, Спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын, Цирк программаларын күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын;

Спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын;

Цирк программаларын күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спектакльләр, концерт-лар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты

стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 август, 562 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, куюу һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 август, 562 нче карары белән расланган Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, куюу һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 август, 593 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче карарындагы 3 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче карарындагы 4 нче пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин